# КАРАР

**28 ноябрь, 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Куркино авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 28 ноябрендә 2 этапта түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Куркино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү системаларын, су суырту манараларын һәм су саклау зоналарын карап тоту, ремонтлау һәм тәэмин итү (су суырту манарасын җылыту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- урам яктырту җайланмасы (урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 65 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 35 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 35 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Куркино авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныйрга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Куркино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Куркино авылының Совет урамындагы юлны төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- су белән тәэмин итү системаларын, су суырту манараларын һәм су саклау зоналарын карап тоту, ремонтлау һәм тәэмин итү, су суырту манарасын җылыту; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Куркино авылының Совет урамында кое өчен будка урнаштыру; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- урам яктыртуны көйләү, ремонтлау, карап тоту; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Куркино авылының урам юл челтәрен карап тоту?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Нырья авыл җирлеге башлыгы: В.И. Павлов